# Тема:

# Синтетик иярчен җөмләләр



# Кушма җөмлә

- Тезмә кушма җөмлә
- Иярченле кушма җөмлә



# Иярченле кушма җөмләләргә синтаксик анализ ясау үрнәге

1. Баш кисәкләр (грамматик нигез) билгеләнә.
2. Җөмлә чикләре күрсәтелә.
3. Баш һәм иярчен җөмләләр ачыклана.
4. Иярчен җөмләнең төзелеше һәм мәгънәсе ягыннан төре күрсәтелә.
5. Иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чаралар билгеләнә.
6. Тыныш билгесе куелу очрагы аңлатыла.
7. Схемасы төзелә.
8. Җөмләнең тулаем төре күрсәтелә.

# Тема:

# Синтетик иярчен җөмләләр

# Синтетик иярчен җөмләләргә мисаллар:

- Әгәр дә син ана телеңне дә, милли культураңны да белмисең икән, синең бу дөньяда беркемгә дә кирәгең юк. (Ренат Харис)
- Җидегән чишмәләргә чиләк куйдым,

  Пар чиләгем тизрәк тулсынга.

  ( Гомәр Бәширов)

- Тел бетү белән, гасырлар буенча килгән гореф-гадәтләр дә, милли әхлак та юкка чыга.

  ( Ркаил Зәйдулла)
- Йортым тәбәнәк булса да,

  Биек әле күкләрем. ( Разил Вәлиев)
- Теләге бар тик тормас. (Мәкаль)

# Синтетик иярчен җөмләләрне бәйләүче чаралар:

- Кушымчалар (килеш, шарт фигыль, сыйфат фигыль, хәл фигыль кушымчалары)
- Бәйлек һәм бәйлек сүзләр
- Янәшә тору чарасы

# җөмләләрдә тыныш билгеләре

- **КАГЫЙДӘ**

***Үзе бәйләнгән сүздән ерак торучы синтетик иярчен җөмлә баш җөмләдән өтер белән аерыла.***

- **МИСАЛЛАР**

1. (1) Сугыш беткәч , (2) батыр күбәер (М.) *(1 нче җөмлә – синтетик иярчен вакыт җөмлә)*

2. (1)Егетнең,(2) үзе үлсә дә,(1)сүзе үлмәс. (М.) *(1 нче җөмлә – синтетик иярчен кире җөмлә)*

# Дәреслек белән эш

- **42 нче күнегүне эшләү.**
- **Бирем: синтетик иярчен кушма җөмләләрне аерып, дәфтәрләргә язарга. Баш һәм иярчен җөмләләрне билгеләргә. Бәйләүче чараларның төрен ачыкларга.**

# Җөмләләрне дәвам итегез:

1. ...-кач, күңелләр күтәрелеп китә.
2. ...-дә, Әлфия тырыша-тырыша шигырь ятлап утыра иде.
3. Карантин булганга,.....



# Җөмләләрнең схемаларын төзергә

1. Укучы мөстәкыйль уйларга өйрәнсен өчен, мәсьәләләр дә бирелә.

2. Дәресләр беткәч, мин спорт секциясенә барачакмын.

3. “Рубин” командасы җиңсә, казан егетләре сөенәчәк.

# Өй эше:

1. Дәреслектәге 46 нчы күнегүне эшләргә.
2. Синтетик иярчен җөмлә турында укырга.



# тест

**1.Кушма җөмлә ул -...**

1) бер яки ике грамматик нигезе  булган җөмлә

***2) ике яки икедән артык грамматик нигезе  булган җөмлә***

3) бер генә грамматик нигезе  булган җөмлә

4) бер яки берничә грамматик нигезе булган җөмлә

**2.  Тезмә кушма җөмлә ул - ...**

1) гади җөмләләре үзара җыючы, каршы куючы яки бүлүче теркәгечләр ярдәмендә генә бәйләнгән кушма җөмлә

2) гади җөмләләре икедән артык җөмлә

3) гади җөмләләре үзара ияртүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнгән кушма җөмлә

***4)  гади җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә***

**3. Иярченле кушма җөмләдә ...**

***1) бер җөмлә икенчесенә  ияреп, буйсынып килә***

2) мөстәкыйль  мәгънәле ике яки икедән артык сүз үзара ачыклаулы мөнәсәбәттә тора

3) ике яки икедән артык иярчен җөмлә бер баш җөмләгә ияреп килә

4) гади җөмләлр арасында ияртүле бәйләнеш тә, тезүле бәйләнеш тә була

**4. Иярченле кушма җөмлә ул-...**

***1) гади җөмләләре үзара ияртү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә***

2) гади җөмләләре үзара санау интонациясе ярдәмендә бәйләнгән кушма җөмлә

3) гади җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә

4) гади җөмләләре ияртү һәм тезү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә

**5. Төзелеше ягыннан иярчен җөмләнең ...**

1) иярчен ия, иярчен хәбәр, иярчен тәмамлык дигән төрләре була

2) синтетик төре генә була

3) аналитик төре генә була

**4*) аналитик һәм синтетик төрләре була***

**6. Тезмә кушма җөмләләрдә бәйләүче чаралар**

**1*)санау интонациясе, каршы кую интонациясе һәм тезүче теркәгечләр***

2) кушымчалар һәм каршы кую интонациясе

3) санау интонациясе, каршы кую интонациясе, күтәрү интонациясе

4)санау интонациясе, каршы кую интонациясе һәм ияртүче теркәгечләр

**7. Аналитик иярчен җөмләләрдә бәйләүче чаралар**

1) кушымчалар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, каршы кую интонациясе

***2) мөнәсәбәтле сүзләр, ияртүче теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр, көттерү интонациясе***

3) парлы яки ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр, көттерү интонациясе һәм тезүче теркәгечләр

4) мөнәсәбәтле сүзләр, ияртүче теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр, санау интонациясе

**8. Синтетик иярчен җөмләләрдә бәйләүче чаралар-...**

1) мөнәсәбәтле сүзләр, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, янәшә тору

2) парлы яки ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр, көттерү интонациясе һәм янәшә тору

***3) кушымчалар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, янәшә тору***

4) кушымчалар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, янәшә тору, көттерү интонациясе

**9. Эше барның ашы бар җөмләсендә нинди тыныш билгесе куела?**

1) өтер куела

***2) тыныш билгесе куелмый***

3)Ике нокта

4) сызык

**10. Кайсы рәттәге җөмләдә тыныш билгесе дөрес куелган?**

1) Бу дөньяда йөрәксезләр бик күп: йөрәгебез шуңа сызлыйдыр. (И.Юзеев)

***2) Бу дөньяда йөрәксезләр бик күп, йөрәгебез шуңа сызлыйдыр. (И.Юзеев)***

1) Бу дөньяда йөрәксезләр бик күп - йөрәгебез шуңа сызлыйдыр. (И.Юзеев)

1) Бу дөньяда йөрәксезләр бик күп йөрәгебез шуңа сызлыйдыр. (И.Юзеев)

# Кушма җөмлә буенча тест нәтиҗәләре



**Бәяләү критерийлары:**

**10- 9 балл – “5”**

**8-7 балл – ”4”**

**6-5 балл - “3”**

**4 һәм кимрәк балл – “2”**

## Тест җаваплары

1) - 2
2) - 4
3) - 1
4) - 1
5) - 4
6) - 1
7) - 2
8) - 3
9) - 2
10) - 2

# Укучылар, булдырдыгыз!!!

